ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
"БЕРЕЗОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ
IV ЧАКЫРЫЛЫШ

КЫРЫК ИКЕНЧЕ СЕССИЯ

КАРАР№ 2

Березовка бистәсе, 2023 елның 13 ноябре

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Березовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 07 июнендәге «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» XXXVII сессиясенең 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы ,Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Березовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Березовка авыл җирлеге

Карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Березовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 07 июнендәге «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»XXXVII сессиясе карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 өлеш "җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә" түбәндәге пункт белән тулыландырырга:

"5) суд пристав – башкаручының башкарма производствоны тәмамлау турында карар чыгару һәм башкарма документны түләтүчегә 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясының 1 өлешендәге 3, 4 пунктларында билгеләнгән очракларда кайтару.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып

чыгарырга(http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https:/ https://bugulma/berezovka.htm /).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районының
«Березовка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Ф. Ф.Сәлманов